КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 2 апрель г.Казань № 208

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2024 елларга Татарстан Республикасында су белән тәэмин итүнең сыйфатын яхшырту буенча төбәк программасын раслау турында» 2019 ел, 30 июль, 636 нчы карары белән расланган 2019 – 2024 елларга Татарстан Республика-сында су белән тәэмин итүнең сыйфатын яхшырту буенча төбәк программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2024 елларга Татарстан Республикасында су белән тәэмин итүнең сыйфатын яхшырту буенча төбәк программасын раслау турында» 2019 ел, 30 июль, 636 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 02 ноябрь, 1000 нче, 2020 ел, 25 февралЬ, 144 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2019 – 2024 елларга Татарстан Республикасында су белән тәэмин итүнең сыйфатын яхшырту буенча төбәк программасына (алга таба – Төбәк программасы) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Төбәк программасы паспортында:

«Төбәк программасы максатлары» юлында «95,54» һәм «98,98» саннарын тиешенчә «95,37» һәм «98,95» саннарына алмаштырырга;

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Төбәк программасын финанслау күләме» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr>
<td>«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Төбәк программасын финанслау күләме</td>
<td>2019 - 2024 елларда Төбәк программасын финанслауның гомуми күләме 1 756 251,1 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:<br>
(мең сум)
<table>
<tr><th rowspan="2">Ел</th><th rowspan="2">Барлык акча</th><th colspan="3">Шул исәптән</th></tr>
<tr><th>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы</th><th>җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы</th><th>бюджеттан тыш акчалар</th></tr>
<tr><td>2019</td><td>80 444,7</td><td>4 822,0</td><td>20 556,8</td><td>55 065,9</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>26 776,0</td><td>0,0</td><td>0,0</td><td>26 776,0</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>215 374,1</td><td>40 921,1</td><td>174 453,0</td><td>0,0</td></tr>
<tr><td>2022</td><td>323 099,4</td><td>53 025,5</td><td>226 055,9</td><td>44 018,0</td></tr>
<tr><td>2023</td><td>283 223,0</td><td>53 812,4</td><td>229 410,6</td><td>0,0</td></tr>
<tr><td>2024</td><td>827 333,9</td><td>41 083,9</td><td>175 149,9</td><td>611 100,1</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>1 756 251,1</td><td>193 664,9</td><td>825 626,2</td><td>736 960,0</td></tr>
</table>
Искәрмә: финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм - аларга, тиешле бюджетларның мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш»;</td>
</tr>
</table>

«Төбәк программасының максатларын һәм бурычларын тормышка ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr>
<td>«Төбәк программасының максатларын һәм бурычларын тормышка ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлында:</td>
<td>Программа чараларын гамәлгә ашыру 2024 ел нәтиҗәләре буенча «Чиста су» федераль проекты паспортында һәм «Чиста су» төбәк проекты паспортында билгеләнгән күрсәткечләргә ирешүне тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк:<br>
үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системаларыннан сыйфатлы эчәргә яраклы су белән тәэмин ителгән Татарстан Республикасы халкының өлеше - 95,37 процент, шул исәптән:<br>
2019 ел - 92,77 процент;<br>
2020 ел - 92,77 процент;<br>
2021 ел - 93,22 процент;<br>
2022 ел - 93,83 процент;<br>
2023 ел - 94,28 процент;<br>
2024 ел - 95,37 процент;<br>
үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системаларыннан сыйфатлы эчәргә яраклы су белән тәэмин ителгән Татарстан Республикасы шәһәр халкының өлеше - 98,95 процент, шул исәптән:<br>
2019 ел - 96,11 процент;<br>
2020 ел - 96,11 процент;</td>
</tr>
</table>

| | |
|---|---|
| | 2021 ел - 96,69 процент;<br>2022 ел - 97,48 процент;<br>2023 ел - 97,86 процент;<br>2024 ел - 98,95 процент.<br><br>Төбәк программасы чаралары яшәү өчен уңайлы мохит булдыруга һәм халыкның яшәешенә ярдәм итәчәк.<br>Бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләрен исәпләү 5 бүлектә китерелгән»; |

Төбәк программасының 2 бүлегендә:
икенче абзацта «95,54» саннарын «95,37» саннарына алыштырырга;
өченче абзацта «98,98» саннарын «98,95» саннарына алмаштырырга;
Төбәк программасының 3 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Төбәк программасын ресурслар белән тәэмин итү

2019 - 2024 елларда Төбәк программасын финанслауның гомуми күләме 1 756 251,1 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:

(мең сум)

| Ел | Барлык акча | Шул исәптән | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы | бюджеттан тыш акчалар |
| 2019 | 80 444,7 | 4 822,0 | 20 556,8 | 55 065,9 |
| 2020 | 26 776,0 | 0,0 | 0,0 | 26 776,0 |
| 2021 | 215 374,1 | 40 921,1 | 174 453,0 | 0,0 |
| 2022 | 323 099,4 | 53 025,5 | 226 055,9 | 44 018,0 |
| 2023 | 283 223,0 | 53 812,4 | 229 410,6 | 0,0 |
| 2024 | 827 333,9 | 41 083,9 | 175 149,9 | 611 100,1 |
| Барлыгы | 1 756 251,1 | 193 664,9 | 825 626,2 | 736 960,0 |

Искәрмә: финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетларның мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.»;
Төбәк программасының 4 бүлегендә:
4.1 пунктта «92,48» һәм «95,54» саннарын тиешенчә «92,77» һәм «95,37» саннарына алмаштырырга;
4.2 пунктта «95,83» һәм «98,98» саннарын тиешенчә «96,11» һәм «98,95» саннарына алмаштырырга;
5 бүлекнең 2 нче таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2 нче таблица

## Бюджет нәтиҗәлелеген исәпләү

| Рейтинг-та позиция | Чара исеме | Татарстан Республикасы халкының гомуми санына китерелгән үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системаларыннан сыйфатлы эчәргә яраклы су белән тәэмин ителгән халык өлешен арттыруның план күрсәткече, процентлар | Федераль бюджеттан инвестиция-ләр күләме, мең сум | Бюджет нәтиҗәлелеге, мең сум /процент |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | ТР Спас муниципаль районының тәүлегенә 5 мең куб метрлы су алу системасы реконструк-циясе | 0,217 | 20 556,82 | 94 731,89 |
| 2. | Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре өчен су җыю үзәге булган су белән тәэмин итү системасын төзү | 0,84 | 187 574,50 | 223 302,98 |
| 3. | Алексеевск муниципаль районының Алексеевск шәһәр тибындагы поселогында су әзерләү станциясен төзү | 0,301 | 69 487,30 | 230 854,82 |
| 4. | Зеленодольск муниципаль районының Васильево шәһәр тибындагы поселогында су әзерләү станциясе төзелеше | 0,445 | 113 065,60 | 254 080,00 |
| 5. | Тәтеш муниципаль районының Тәтеш шәһәрендә су әзерләү станциясе төзелеше | 0,288 | 74 906,00 | 260 090,28 |
| 6. | Чирмешән муниципаль районының Чирмешән авылында су әзерләү станциясен төзү | 0,166 | 53 507,30 | 322 333,13 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 7. | Питрәч муниципаль районының Питрәч авылында су әзерләү станциясен төзү | 0,251 | 88 572,80 | 352 879,68 |
| 8. | Зеленодольск муниципаль районының Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогында су әзерләү станциясен төзү | 0,197 | 121 905,00 | 618 807,11 |
| 9. | Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогында су әзерләү станциясен төзү | 0,113 | 96 050,90 | 850 007,96 |
| Барлыгы | | 2,818 | 825 626,22 | 292 983,05 |

Төбәк программасын гамәлгә ашыруны финанс ягыннан тәэмин итү аңа 2 нче кушымтада бирелгән.»;

Төбәк программасына 1 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

Төбәк программасына 2 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

Төбәк программасына 3 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

Төбәк программасына 4 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

Төбәк программасына 5 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин